**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30.01.2026 № 101

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәрендә җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән Исемлеге хакының иң чик күләмен раслау турында

«Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, шулай ук 2026 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффицентын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елның 01 февраленнән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәрендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен әлеге карарга 1нче кушымта һәм 2нче кушымта нигезендә 9 678 сум 63 тиен күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәрендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән Исемлеге хакының иң чик күләмен раслау турында» 2025 елның 28 гыйнварындагы 85 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 01 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 30 гыйнварындагы 101 номерлы карарына 1нче кушымта

2026 елның 01 февраленнән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәрендә Нурлат шәһәрендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе

| № | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. | Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны китереп бирү | 3 228,91 |
| 3. | Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 1 862,83 |
| 4. | Җирләү хезмәте (кабер казу һәм җирләү ) | 4 586,89 |
| | Барлыгы | **9 678,63** |

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының
2026 елның 30 гыйнварындагы 101 номерлы карарына
2нче кушымта

## 2026 елның 01 февраленнән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәрендә Нурлат шәһәрендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе

| № | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. | Мәетне кәфенләү (төрү) | 1 490, 27 |
| 3. | Җирләү өчен кирәкле әйберләрне бирү һәм китерү | 1 738,64 |
| 4. | Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 1 862,83 |
| 5. | Җирләү хезмәте (кабер казу һәм җирләү ) | 4 586,89 |
| | Барлыгы | **9 678,63** |